РТ г. Альметьевск
МБДОУ №53 “ Светофорик”

Тема: “Хат ташучы һөнәре”
(средняя группа)

Авторы:
Ракипова Ляйсина Фирдинантовна
Базина чулпан Инсафовна

Уртанчылар төркеме.
Тема: “Хат ташучы һонәре”

Максат: балаларны почта тарихы белән таныштыру һәм хат ташучы һөнәре турындагы белемнәрен ныгыту.

Тәрбия бурычлары: хат ташучы хезмәтенә хөрмәт тәрбияләү.

Үстерү бурычы: балаларның истә калдыру сәлатен , хәтерен үстерү, шаблон һәм декоратив материал белән эшләүне ныгыту.

Белем бирү бурычлары: хат ташучы турында булган белемнәрен баету, яңа сүзләрне бәйләнешле сөйләмдә кулланырга өйрәтү

Төп белем бирү өлкәсе: танып белү.

Интегральь белем бирү өлкәләре: сөйләм телен үстерү, нәфис – нәфасәти үсеш (кисеп ябыштыру), физик үсеш, социаль – коммуникатив үсеш.

Методик алымнар һәм чаралар: слайд күрсәтү, хәрәкәтле уен, практик эш, сөенеч мизгеле, сорау, мактау, бәяләү.

Җиһазлау: презентация, хат ташучы сумкасы, конвертлар, газета, открытка, хатлар, журналлар, һәрбер балага кәгазь битләре, клей, клей өчен кисточка, төсле рәсемнәр, маркалар, салфеткалар.

Сүзлек өстендә эш: *почта хезмәте, адреслар, маркалар*

Алдан үткәрелгән эш: һөнәрләр турында сөйләшү, “Простоквашино” мультфильмын карау

Эшчәнлек төзелеше:

1. Оештыру.
2. Сөенеч мизгеле.
3. Танып – белү эшчәнлеге.
4. Ял минуты.
5. Продуктив эшчәнлек. Конвертны ябыштыру.
6. Йомгаклау.

Эшчәнлек барышы

Тәрбияче. Балалар бу кемнең сумкасы? Сезнекеме?

Балалар.Юк

Тәрбияче. Балалар бу сумка табибныкыдыр? Безнең группага табиб кереп чыккан һэм сумкасын оныткандыр?

Тәрбияче. Эйдәгез сумканы ачып карыйк, бәлки анда берәр билге табарбыз. Бу нәрсә?

Балалар. Бу газета, журнал, открытка, хатлар

Тәрбияче. Бик дорес. Балалар ә кем аны калдырган?

Балалар. Хат ташучы

Тәрбияче. Балалар, хат ташучы кайда эшли?

Балалар. Почтада

Тәрбияче. Дөрес балалар, хат ташучы почтада эшли. Балалар карагыз эле, хат ташучының узенен формасы, баш киеме һәм сумкасы бар (курчакны күрсәтеп)

Тәрбияче. Балалар, сезнең беләсе килэме почта һәм хат ташучы һөнәренең кайдан килгәнлеген?

Балалар. Әйе.

Тәрбияче. Балалар, безнең бер мультфильмда нинди куренекле хат ташучы бар эле?

Балалар. Хат ташучы “Печкин”

Тәрбияче. Бик дөрес. Ә хәзер балалар барыбызда экранга карыйк.

Экранда хат ташучы Печкин сүрәте. Почта турында тарихны хат ташучы “Печкин” сөйли.

Элек электән үк кешеләрнен бер берсе белән сөйләшү теләге булган. Кешеләр укырга, язарга өйрәнгәч, бу мәсәьлә юкка чыккан. Беренче хатларны ташларда , ә аннары каен тузына язганнар. Соңыннан гына кәгазь уйлап тапканнар. Хатларны төрле шәһәрләргә җир өстеннән генә түгел, диңгез өстеннән дә илтәргә кирәк булган. Тиздән хатлар бик күбәйгән, шуңа күрә почта хезмәтен ачканнар, алар хатлар, газеталар, журналлар, посылкаларны төрле төбәкләргә җибәрә башлаганнар. Башта почтаны атлар ярдәмендә, аннары тимер юл буенча җибәргәннәр. Соңыннан һавадан очкычлар ярдәмендә җибәрә башлаганнар. Бу барлык почтаны хат ташучылар һәрбер өйгә таратканнар. Э хәзерге вакытта безнен ойлэрдэ копьютерлар бар, хатларны электрон почта аша да жибэреп була.

Печкин. Балалар, мин сезнен төркемдә уземнен сумкамны онытып калдырганмын. Сумка эчендә газета, журналлар,открыткалар һәм хатлар бар. Бу почтаны конвертларга салып куярга кирәк. Мин сездэн ярдэм сорыйм.

Тәрбияче. Әйдәгез әле бергәләп, Печкинга булышыйк. Сез һәрберегез дә хат ташучы булырсыз. Моның өчен безгә ике командага бүленергә кирәк. Беренче команданың өстәлендә открыткалар һәм газеталар, ә икенче команданың өстәлендә хатлар һәм журналлар ята. Минем сигнал буенча һәрбер команда кирәкле почтаны тиешле конвертларга салырга тиеш. Дорес һәм тиз эшләүче команда җиңүче була.

Уен барышында музыка уйнатыла.

Тәрбияче. Булдырдыгыз балалар, барыгыз да бик дөрес эшләдегез.

Тәрбияче. Балалар безнен хат ташучылар аргач һәр вакытта да гинмастика ясаганнар. Әйдәгез әле, без дә сезнең белән ял итеп алыйк.

Физкультминутка

Җил исә, исә – исә,

Агачларны селкетә.

Җил тына – тына, тына,

Ә агачлар үсә – үсә.

Тәрбияче. Балалар, безнең ишеккә кемдер шакый. Кем икән анда?

Печкин. Исәнмесез балалар! Мин үземнең сумкамны сезнең төркемдә онытып калдырганмын.

Тәрбияче. Бу синең сумкаң менә Печкин. Балалар сиңа ярдәм иттеләр, почтаңны кирәкле конвертларга тутырып куйдылар.

Печкин. Бик зур рәхмәт сезгә, балалар! Мин дә сезгә буш кул белән килмәдем. Әйтегез әле миңа, тиздән нинди бәйрәм?

Балалар. Яңа ел.

Печкин. Балалар, ә сез беләсезме Яңа ел алдыннан барлык балалар да Кыш бабайга хатлар язалар.

Балалар. Әйе.

Печкин. Э бу язган хатларны без кайда салабыз?

Балалар. Конвертка.

Печкин. Дорес, менә без дә сезнең белән үзебезнең хатлар өчен конверт ясап бизәрбез. Сез ризамы?

Балалар. Әйе.

Печкин. Балалар, карагыз әле мин үземдә Кыш бабайга хат яздым һәм конвертка салдым. Хатымны җибәрер өчен конвертка марка да ябыштырдым, адресымны да яздым. Һәрбер конверткада адрес язылырга тиеш: шәһәр, урам исеме, торган йортның номеры булырга тиеш. Әгәрдә конвертка марка ябештерелмәсә, адресы язылмаса ул тиешле урынга барып җитми. Мин сезгә дә маркалар алып килдем.

Печкин. Ә хәзер әйдәгез бергәләп эшне, эшне башлыйк.

Печкин. Минем кулымда кәгазь бите. Сезнен остәлләрдә дә кәгазь битләре ята. Элеге кәгазь битләрен сызыклары буенча бөклибез, кисточканы клейга манып, клейны элеге бокләнгән кәгазьгә буибыз һәм ябештерәбез. Шулай итеп ябештерсәк, безнең конверт килеп чыгар. Аннан соң конвертның өске уң ягына марканы, ә аскы сул ягына мин алып килгән рәсемне ябештерәбез.

Эш барышында музыка уйный.

Печкин. Булдырдыгыз, балалар. Кич белән өйгә кайткач, үзегезнең адресны язып, әти- әниегез белән хатны почтага илтерсез.

Печкин. Балалр, мин тагын бер кат сезгә үземнен рәхмәтеңне әйтәм, миңа сумкамдагы почтаны төрле адресларга таратырга кирәк.

Печкин. Сау булыгыз!

Балалар. Сау бул!

Тәрбияче. Балалар без бүген нинди хөнәр белән таныштык? Балалар, хат ташучы һөнәре нинди кирәкле һәм кызыклы. Хат ташучы һөнәре кирәклеме? Балалар без буген нинди яңа сүзләр белән тыныштык?

Тәрбияче. Балалар, күрәсезме без хат ташучы һәм почта хезмәте турында бик куп белдек. Өйгә кайткач бу хөнәр турында кемгә сөйлисез? Ә сез тагын нинди һөнәр белән танышыр идегез?

Кулланылган әдәбият

1. Балалар бакчасында бердәм белем бирү эшчәнлеге: балалар бакчасы тәрбиячеләре өчен методик кулланма /З. М. Зарипова, А. Х. Габдрахимова, А. Т. Миникаева. – Казань: Первая полиграфическая компания, 2013. – 240 с.

2. От рождения до школы. Примерная общеобразовательная программа дошкольного образования /пилотный вариант/ /Под. ред. И. Е. Вераксы, Т. С. Комаровой, М. А. Васильевой. – 3-е изд., испр. И док. – М.: МОЗАИКА – СИНТЕЗ, 2014. – 368 с.

3. Балалар бакчасында әдәп – әхлак тәрбиясе: методик кулланма / К. Г. Закирова, Р. Ә. Кадырова, Г. М. Сафиуллина. – Казан: Беренче полиграфия компаниясе, 2013. – 424 б.

4. Туган телдә сөйләшәбез: 5 -7 яшьлек балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү буенча методик ярдәмлек / Төз.: З. М. Зарипова, Л. Н. Вәҗиева, Р. С. Зөфәрова h. б. – Казан: ФОЛИАНТ, 2012. – 304 б.